РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 12 декабре г. Буа шәһәре 5-48 номерлы

Хәрби комиссариатлары булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен ТР Буа муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр бирү Кагыйдәләре турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142 нче статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләр бирү Кагыйдәләрен расларга
2. Әлеге карар Нигезләмәләре 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына бюджетлардан башлап, бюджет төзегәндә, раслаганда һәм үтәлгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә йөклим.

Буа муниципаль районы
башлыгының беренче урынбасары,
Совет рәисе урынбасыры И.Ф. Еремеев

2019 елның 12 декабрендәге 5-48 номерлы
ТР Буа муниципаль районының Советы карары белән
РАСЛАНГАН

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләр бирү
Кагыйдәләре

1. Әлеге кагыйдәләр Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджетыннан Буа муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына хәрби комиссариатлар (алга таба – субвенцияләр, җирлек) булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен субвенцияләр бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Субвенцияләр хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатларында җирлекләр бюджетларына бирелә.

3. Җирлекләр бюджетларына субвенцияләр бирү чыгымнарын финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы- ТР  Буа муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган хәрби комиссариатлары булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан субвенция.

4. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) әлеге Кагыйдәләр нигезендә бирелә торган бюджет акчаларын баш бүлүче булып тора.

5. Җирлек бюджетына субвеция күләме хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә  беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен муниципаль район бюджетыннан җирлек бюджетына субвенция күләмен билгеләү методикасы нигезендә «Татарстан Республикасы муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарына хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә  беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен исәпләү һәм муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына субвенцияләр бирү турында » 2006 елның 11 декабрендәге 78 –ТРЗ номерлы Законга 1 нче кушымта нигезендә билгеләнә.

6. Муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына субвенцияләр бүлү Буа муниципаль районы Советының тиешле финанс елына һәм план чорына муниципаль район бюджеты турындагы карары белән раслана.

7. Субвенцияләр тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм Башкарма комитетка билгеләнгән тәртиптә әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында каралган максатларга бирелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә җирлекләр бюджетларына бирелә.

8. Субвенцияләр түбәндәге чыгымнарны гамәлгә ашыру өчен җирлекләр бюджетларына бирелә:

хезмәткә түләү фондына тиешле түләүләрне дә кертеп, хәрби-учет хезмәткәрләренә хезмәт хакы  түләү өчен;

биналарны арендалау өчен түләү;

элемтә хезмәтләре өчен түләү;

транспорт хезмәтләре өчен түләү;

командировка чыгымнары;

коммуналь хезмәтләр өчен түләү;

җиһаз, инвентарь, оргтехника, элемтә чаралары, чыгым материаллары белән тәэмин итү.

9. Субвенцияләрне тоту Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль органнарының (алга таба – Казначылык) шәхси счетлары аша башкарыла.

10. Башкарма комитет Казначылыктан финанслауның иң чик күләмнәрен билгеләү өчен чыгым расписаниесен алганнан соң, җиде эш көне эчендә Казначылыкка субвенцияләр исәбеннән җирлекләр бюджетларына субвенцияләр күчерү өчен касса чыгымына заявка бирә.

11. Җирлекләрнең җирле үзидарә органнары хисап чорыннан соң килүче квартал саен, айның 5 числосыннан да соңга калмыйча, Башкарма комитетка хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә, финанс тәэминаты чыганагы субвенция булган территорияләрдә, Россия Федерациясе Оборона министрлыгы белән килешү буенча Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән форма буенча, җирлекләр бюджетлары чыгымнары турында хисап тапшыралар.

12. Башкарма комитетка тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплылык җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына йөкләнә.

13. Субвенцияләр бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә муниципаль район бюджеты кеременә күчерелергә тиеш.

14. Субвенцияләр бирү елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына файдаланылмаган субвенциянең калган өлеше Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә муниципаль район бюджеты керемена кире кайтарылырга тиеш.

15. Субвенцияләр максатчан характерга ия һәм, әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында күрсәтелгәннәрдән тыш, башка максатларда кулланыла алмый.

16. Субвенцияләрнең максатчан кулланылышын контрольдә тотуны законнар нигезендә Башкарма комитет һәм муниципаль районның финанс органы башкара.

---